УДК 930.27:94(470.41) DOI: 10.22378/he.2018-3-2.334-344

# СОҢГЫ ЕЛЛАРДАГЫ ЭПИГРАФИК ТАБЫШЛАР: Ш. МӘРҖАНИ ГАИЛӘСЕ

***А.М. Гайнетдинов***

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең*
*Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты*
*Казан, Россия Федерациясе*
*aydargm@yandex.ru.*

Мәкаләдә Казан шәһәренең Яңа Татар бистәсе зиратында сакланган XIX–XX гасыр башы татар каберташлары тасвирлана. Бу ташбилгеләр галим Шиһабетдин Мәрҗани һәм аның гаиләсе әгъзалары каберләренә куелган. 2017 елда Татарстан Фәннәр академиясенең Тарих институты Казан шәһәренең Яңа Татар бистәсе зиратында сакланган эпиграфик истәлекләрне барлау һәм өйрәнү максатында экспедиция оештырды. Эш барышында күренекле галим, дин эшлеклеләре каберташларын табып, язулары укылды; шул исәптән Ш. Мәрҗан каберенә куелган ташбилге дә өйрәнелде. Мәкаләдә автор Шиһабетдин Мәрҗани һәм аның гаиләсе әгъзалары каберләренә куелган ташбилгеләрнең текстларын да китерә.

**Төп төшенчәләр:** Шиһабетдин Мәрҗани, Мәрҗани гаиләсе, каберташлар, зиратлар, эпиграфичек истәлекләр, Яңа Татар бистәсе зираты.

Күренекле татар галиме Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889) шактый күп фән өлкәләрен яхшы белгән, шул исәптән эпиграфика тармагында да үзен чын белгеч буларак таныткан. Ул кечкенәдән үк эпиграфик истәлекләр белән кызыксына башлаган: үсмер чагында ук авылыннан ерак түгел бер җирдә урнашкан кабер ташларының текстларын укып кайткан булган [3, б. 25]. Мәрҗани байтак борынгы кабер ташларын ачыклаган һәм үзенең мәшһүр «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исемле хезмәтендә аларның тулы текстларын теркәп калдырган. Кызганыч, галим тапкан эпиграфик материалларның күпчелеге бүгенге көнгә хәтле сакланып калмаган.

Ш. Мәрҗанинең ташбилгеләргә карата мөнәсәбәтен белү өчен, беренче чиратта, үзенең әйтеп калдырган васыятьләренә игътибарыбызны юнәлтик. Мәрҗани үләренә өч ай кала, ягъни 1889 елның 25 гыйнварында, шәкерте мулла Гобәйдуллага хат белән түбәндәге васыятен язган: «Үлсәм, каберемә бер таш яздырып куй. Бик кечкенә, бер-ике кеше генә күтәреп китәрлек булмасын. Һәм рус сүзе, рус елы куелмасын» [3, б. 191]. Димәк, Ш. Мәрҗани кабер өстенә таш куюга карата уңай караган һәм шәригатьтә моны тыючы дәлилләр тапмаган. Ул ташның зурысын да, кечесен дә кую-

да бернинди начарлык күрмәгән, үзенең каберенә ике кеше күтәрә алмаслык дәрәҗәдәге зур таш куюларын сораган.

Галим Урта Азия суфиларының каберләрне артык олылауларын, мәетләрдән ярдәм сорауларын яратмаган. Бу турыда Ш. Шәрәф түбәндәгечә язган: «Бохараның дәрес тәртипләрен һәм байтак кагыйдәләрен яратмады. Бохара халкының каберләрен артык олылауларына, мәетләрдән ярдәмбулышлык сорауларына бик эче поша иде. Бервакыт янгын булганда, шундагы халыкның: Йа, Хуҗа Баһаведдин, ярдәм ит», – дип кычкырып торуларын күреп: «Безнең авыл халкы болардан байтак югары. Ярдәмне Аллаһтан сорыйлар. Тәкбир һәм азан әйтәләр», – дияргә теләгән иде [9, б. 85].

XIII гасырдан башлап татар кабер ташларына, мәет хакындагы мәгълүматтан тыш, Коръән аятьләре язу киң таралыш тапкан. Аятьләр белән бергә кайбер очракларда Мөхәммәд пәйгамбәрнең сүзләре, ягъни хәдисләр язылган. Бу күренеш бигрәк тә Казан ханлыгы чоры эпитафияләре өчен хас. Шунысы кызык: милләтебезнең мәшһүр дин галимнәре, шул исәптән Ш. Мәрҗани, кабер ташларына Коръән-хәдистән нәрсә дә булса язуны өнәп бетермәгәннәр. Шул сәбәпледер, олуг галимнәр Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдин, Г. Баруди һәм аларның туганнары белән бәйле кабер ташларында Коръән аятьләре язылмаган. Мәрҗани үзе ясатып куйган ташбилгеләрнең берсендә дә Коръән аятьләре һәм хәдисләр язылмаган, димәк, моны ул кирәкле эш дип санамаган.

Галим кабер ташларына фәкать гарәп телендә һәм даталарны да һиҗри ел исәбе белән язу яклы булган. Ул үзе моны: «Һиҗри ел исәбе – сәхабәләрнең үзара килешүләре белән мөселманнар өчен һәртөрле мөгамәләләрендә тотуны һәм гамәлдә куллануны тиешле күргән ел исәбе», – дип аңлаткан [1, б. 555]. Шуңа күрә Мәрҗани үзе ясаткан кабер ташларындагы текстларның барысы да гарәп телендә һәм даталары милади ел исәбе белән бирелмәгән.

Кыскасы, Шиһабетдин хәзрәт белән бәйле ташъязма истәлекләрне җентекләп өйрәнү, анализлау аша, аның кайбер фикер-карашларын ачыкларга, башка төрле чыганаклардан ала алмаган мәгълүмат тупларга мөмкин.

Мәрҗани белән бәйле эпиграфик истәлекләрне өйрәнү максатыннан, без Казан шәһәренең Яңа бистә каберстанында хәзерге көннәргә кадәр сакланып калган бөтен ташъязма истәлекләрне барлау өчен 2017 елда фәнни экспедициягә чыктык. Казан шәһәренең әлеге зиратында Мәрҗанинең үзенә, аның бер хатыны, ике улы, ике кызына куелган кабер ташлары табылды.

Галимебез кабер ташының тексты түбәндәгечә:

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Мәрхүм Шиһабеддин бине Баһаэддин
2) Мәрҗани
3) хәзрәтләринең җәмегъ итдеге асаре
4) фазыл вә кәмалинә борһан катыйгдыр бәлдәи Казанда
5) кырык сәнә микъдары ләвазиме имамәт вә нәшре голүм идеб

6) 1306 сәнә һиҗриййә шәгъбан мөбарәкнең ахыр йәүмендә
7) 73 синнендә иртихаль даре бәка әйләде рахимәһүллааһү Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (диагональ буенча уеп язылган):
1) «Нәзым
2) әл-мәүтү фииһи күллүн-нәәси йәштәрикүү
3) вә ләә сүүкатүн йәбкаа вә ләә мәлик».

Сул ягы (диагональ буенча уеп язылган):
1) «Нәзым
2) ә-ләә иннәмәәд-дүнйәә кә-зыйлли сәхәәбәтин
3) әзалләткә йәүмән сүммә ганкә идъмәхәлләт
4) фә-ләә тәккә фәрхәәнән биһәә хиинә әкъбәләт
5) вә ләә тәккә җәзәгаанән ләһәә хиинә вәлләт».

Арткы ягы (уеп язылган):
1) «Мәшһәдүл-имәәми галләәмәтил-гаалими
2) саахибит-тәсааниифвиф-
3) -ил-фәәикати вәт-тәхкыйкаатир-раaикати Шиһабеддин бине
4) Баһаэддин әл-Мәрҗани иртәхәлә иләә рахмәти
5) Раббиһи тәгаммәдәһү Сүбхәәнәһү би-гафвиһи вә кәрамиһи гашиййәтә йәүмил-әхәди
6) ли-ләйләтин бәкыййәтин мин шәгъбәәнин сәнәтә 1306
7) ситтә бәгъдә әлфин вә сәләәсәмиъәтин минәл-һиҗраһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе:

Алгы ягы: «Мәрхүм Шиһабеддин бине Баһаведдин Мәрҗани хәзрәтләренең җыйган әсәрләре – хөрмәт һәм камиллегенә катгый дәлил. Казан шәһәрендә кырык ел микъдары имамлык вазыйфаларын [үтәп] һәм гыйлемнәр таратып, һиҗри 1306 ел мөбарәк шәгъбаненең ахыргы көнендә 73 яшендә мәңгелек дөньяга күчте. Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Шигырь: Үлем алдында һәр кеше бертигез, гади халык та, патша да».

Сул ягы: «Шигырь: Чынлыкта, дөнья болыт күләгәсе кебек: бүген сине күләгәдә тота, соңыннан югала. Ул килгән вакытта, аңа шатланма һәм, ул киткән чакта, аның өчен кайгырма».

Арткы ягы: «Имам, күренекле галим, бик яхшы әсәрләр һәм гүзәл хезмәтләр иясе Шиһабеддин бине Баһаведдин Мәрҗани кабере. Раббысы рәхмәтенә (Аллаһ Сөбханәһү аны гафу итсен һәм хөрмәтләсен) кич белән якшәмбе көн һиҗри 1306 (мең өч йөз алтынчы) елның шәгъбаны тәмамланырга бер төн кала күчте».

Таш үлчәмнәре: 206(223)x52–55x35–38. Мәрҗанинең кабере зиратның 15 һәм 16 нчы аллеялары арасында.

Ш. Мәрҗани каберенә көрән төстәге граниттан эшләнгән мәһабәт таш куелган. Ташның тексты гарәп графикасында татар һәм гарәп телләрендә язылган, вафат булу датасы һиҗри ел исәбе белән күрсәтелгән.

1911 елда Ризаэтдин Фәхретдин якын дусты һәм фикердәше Галимҗан Баруди белән бергә Мәрҗани каберен зиярәт кылган. Шул вакытта ул ташның тулы текстын язып алып, аны үзенең хезмәтендә теркәп калдырган [7, б. 179–180]. Әмма Р. Фәхретдиннең тексты белән хәзерге вакытта сакланган таш тексты арасында бераз аерма бар. Мәсәлән, аның укылышыннан аермалы буларак, «Мәәтәл-гаалимү вә мәәтәл-гааләм» җөмләсе хәзерге ташта юк. Шулай ук «Рахимәһүллааһү Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ» җөмләсендә Р. Фәхретдин текстында «Тәгааләә» сүзе төшеп калган. Башка җирләре исә туры килә. Димәк, Мәрҗани вафат булганнан соң куелган кабер ташы соңыннан икенчегә алыштырылган, дип әйтергә нигез бар.

Галимнең беренче ташы Гобәйдулла исемле шәкерте тарафыннан утыртылган булган [6, б. 420]. XX гасыр башында Мәрҗани кабер ташының тузган булуы хакында Борһан Шәрәф болай язып калдырган: «“Шиһаб ахунд”ның кабер ташы берничә заманнар Казан мәкъбәрәсендә иң гүзәл таш булып торган иде. Инде таш өстендәге тулы айның алтыны бетеп, бөтенләй кызганыч хәлдә калган» [8, б. 759]. Элек Мәрҗанигә куелган таш өстендә тулган ай торган. Г. Тукай үзенең мәшһүр «Шиһаб хәзрәт» шигырендә юкка гына галимне тулган ай белән чагыштырмаган.

Әле 2017 елга хәтле ул тулган ай бар иде, ләкин узган ел аны ак төстәге ярымай сурәтенә алыштырып куйганнар. Әгәр дә элеккесе урынына тагын шундый ук яңа тулган ай сурәте куйган булсалар, яхшырак һәм дөресрәк булыр иде.

Мәрҗанинең дүрт хатынының бары тик – Нәгыймә Хөсәен кызының гына кабер ташы ачыкланды. Таштагы текстының укылышы түбәндәгечә:

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Нәгыймә
2) бинтел-Хөсәйен мөхәккыйк мәшһүр
3) Шиһабеддин әл-Мәрҗани никахында
4) 19 йыл микъдары мәгыйшәт идүб зөлкагдә-
5) -нең 2 сендә 1283 сәнә иртихаль бәгъдендә
6) ошбу мәкъбәрәдә дәфен иделде
7) рахимәһәәллааһү рахмәтән вәәсигаһ».

Уң ягы (уеп язылган):

1) «Гаруусүл-мәшһәди
2) вә әнүүсүл-мәркадил-кәриимәти
3) Нәгыймә бинтел-Хөсәйен
4) интәкаләт иләә дәәрил-караари
5) вә җәннәәти тәҗрии мин тәхтиһәә-
6) -л-әнһәәр».

Сул ягы (уеп язылган):

1) «Сәнәтә әлфин вә миъәтәйни

2) вә сәмәәниинә ли-әрбәгый
3) халәүнә мин зиил-кагдәти
4) сабәәхә йәүмил-әрбәгааъ».

Арткы ягы (уеп язылган):

1) «Миладиййә илә 1871 нче йылда
2) 14 нче гыйнварда мәрхүмә Нәгыймә вакты сәхәрдә
3) вафат улды Хак Тәгалә гарикы рәхмәт
4) әйләйә зәүҗ мөхтәрәме Мәрҗани хәзрәтләринең
5) иртәсе көн вирде лисан итдеге шигырь
6) вә әмсиинәә ләнәә әһл кә-хайраати би-фирдәүс
7) вә әсъбәхүнәә ләнәә[1] әһл кә-әннә ләм тәганн бил-әмс».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе: Алгы ягы: «Нәгыймә бинте Хөсәен, хаклыкны эзләүче мәшһүр Шиһабеддин Мәрҗани никахында 19 ел яшәп, [һижри] 1283 елның 2 зөлкагдәсендә вафат булганнан соң, бу кабердә җирләнде. Аллаһ аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Уң ягы: «Кабер кәләше һәм хөрмәтле кабер кызы Нәгыймә бинте Хөсәен ахирәт йортына һәм асларыннан елгалар агучы җәннәтләргә күчте».

Сул ягы: «Сәнәтә әлфин вә миъәтәйни вә сәмәәниинә ли-әрбәгый халәүнә мин зиил-кагдәти сабәәхә йәүмил-әрбәгааъ».

Арткы ягы: «Милади белән 1871 елның 14 гыйнварында сәхәр вакытында мәрхүмә Нәгыймә вафат булды. Хак Тәгалә рәхмәткә күмсен. Мөхтәрәм ире Мәрҗани хәзрәтләренең иртәнге көндә телендә кабатланып торган шигыре: Йокыга киттек һәм безнең Фирдәвес җәннәтендәге нигъмәт кебек хатыныбыз бар иде, Йокыдан тордык һәм хатынсыз без, әйтерсең, кичә ул булмаган да».

Таш үлчәмнәре: 111(142)х40х22. Кабере 22 нче аллея һәм зират киртәсе арасында.

Әлеге кабер иясенең шәҗәрәсе түбәндәгечә: Нәгыймә бинте Хөсәен бине Йосыф бине Исмәгыйль бине Апанай. Ул һижри 1247 елның шәгъбан аенда, милади 1831 елда Казан шәһәрендә дөньяга килгән [2, б. 362]. Бибинәгыймә – Ш. Мәрҗанинең икенче өекле хатыны. Шиһабетдин хәзрәт аңа һижри 1268 елның зөлкагдәсендә (милади 1852 елның сентябрендә) өйләнгән [2, б. 362]. Нәгыймәнең кабер ташы текстында ялгышлык киткән: вафат булуы һижри 1283 елда дип күрсәтелгән, чынлыкта исә милади 1871 ел һижри 1287 елга туры килә.

Мәхмүд Шиһабеддин улы Мәрҗанигә куелган кабер ташы тексты түбәндәгечә:

Алгы ягы (калкытып язылган):

1) «Мәшһәд-

[1] Биредә хата киткән: «ләнәә» урынында «биләә» сүзе булырга тиеш.

2) - үш-шәәббил-галләәмәти
3) Бaһаэддин Әбүл-Фазыл
4) Мәхмүд бине Шиһабеддин
5) әл-Мәрҗани интәкадә иләә
6) рахмәти Раббиһи сәхәра йәүмил-хамииси ли-гашрин
7) халәүнә мин шәһри рабиигыйль-әүвәли
8) сәнәтә 1303 сәлә[сә] бәгъдә әлфин вә сәләәсәмиъәтин минәл-һиҗраһ».

Уң ягы (уеп язылган): «Иләәһии габдүкәл-гаасыый әтәәкә мүкыйрран биз-зүнүүби фә-кад дәгаакә фә-ин тәрхәм фә-әнтә әһлүн ли-зәәкә вә ин тәтъруд вә мән йәрхәм сивәәк».

Сул ягы (уеп язылган): «Йәә вәәкыйфән би-кабрии мүтәфәккиран би-әмрии бил-әмси күнтү мислүкә гадән тәсыыйру мислии».

Арткы ягы (уеп язылган):

1) «Вәәдыйгу
2) һәзәәл-ләүхи
3) вәәлидүһү Шиһабеддин
4) бине Баһаэддин
5) әл-Мәрҗани сәнәтә 1306
6) ситтә бәгъдә әлфин вә сәләәсәмиъәһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе:

Алгы ягы: «Күренекле яшь галим Баһаведдин Әбел-Фазыл Мәхмүд бине Шиһабеддин Мәрҗани Раббысы рәхмәтенә таң атканчы пәнҗешәмбе көн һиҗри 1303 (мең өч йөз өченче) елның унынчы рабигыль-әүвәлендә күчте».

Уң ягы: «Илаһым, синең гөнаһлы колың Синең яныңа гөнаһлар белән килде һәм Сиңа ялварды. Әгәр рәхим кылсаң, Син моны эшли аласың, әгәр куып җибәрсәң, Синнән башка кем рәхим кылсын».

Сул ягы: «Әй, минем каберем янында басып торучы, минем хәлем хакында фикерләүче, кичә мин синең кебек идем, таңда син минем кебек булырсың».

Арткы ягы: «Бу ташны куючы: аның атасы Шиһабеддин бине Баһаведдин Мәрҗани, 1306 (мең өч йөз алтынчы) ел».

Таш үлчәмнәре: 134x36x18. Кабере зиратның 15 һәм 16 нчы аллеялары арасында.

Әлеге кабер иясе – Ш. Мәрҗанинең сөекле улы. Ул һиҗри 1283 елның 27 җөмадиәл-әүвәлендә (1866 елның октябрендә) дөньяга килгән [2, б. 350]. Бик зиһенле булуы сәбәпле, Мәрҗани аңа бик күп өметләр баглаган булган. «Мөстәфадел-әхбар» китабында Мәхмүдкә атасы түбәндәгечә характеристика биргән: «Гаять акыллы, сабыр, укырга бик ярата торган, яхшы хәтерле, күп нәрсәне яттан белгән, бик күп яхшы сыйфатларны үзендә туплаган, нечкә билле, матур йөзле, төз һәм озын буйлы, кара каш-

лы, кара күзле, кара чәчле кеше иде» [2, б. 350]. Кызганыч, Мәхмүд аягына салкын тидереп, бер аягын ампутацияләгәннәр, соңрак, инде дәваланды дигәндә генә, туберкулез авыруы белән чирли башлап, бик яшьли вафат булган. Кабер ташындагы тексттан аңлашылганча, Мәхмүднең икенче исеме, ягъни кушаматы – Бәһаветдин, күньясе – Әбел-Фазыл.

Борһанеддин Шиһабеддин улы Мәрҗанигә куелган ташъязманың укылышы:

Алгы ягы (калкытып язылган):

1) «Әл-хүкмү лилләәһ
2) түвүффийәш-шәйху Борһанеддин
3) Мөхәммәд бине Шиһабеддин әл-Мәрҗани фии гашиййәти
4) йәүмил-әрбәгааъи ли-ихдәә гашәра ләйләтән халләт мин
5) җүмәдииәл-үүләә әрбәга вә сәләәсиинә бәгъдә әлфин вә сәләәсәмиъәһ».

Арткы ягы (уеп язылган):

1) «Җәгаләллааһү Тәгааләә
2) кабраһү раудатән мин рийәәдыйль-җәннәһ
3) Борһанеддин хәзрәт Казан шәһәрендә
4) 35 йыл микъдары имамәт вә тәдрис илә
5) гомер кичүреб 62 йәшендә даре бәкайә кайтды».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе:

Алгы ягы: «Хөкем Аллаһта. Шәех Борһанеддин Мөхәммәд бине Шиһабеддин Мәрҗани кич белән чәршәмбе көн мең өч йөз утыз дүртенче елның унберенче җөмадиәл-әүвәлендә вафат».

Арткы ягы: «Җәгаләллааһү Тәгааләә кабраһү раудатән мин рийәәдыйль-җәннәһ Борһанеддин хәзрәт Казан шәһәрендә 35 йыл микъдары имамәт вә тәдрис илә гомер кичүреб 62 йәшендә даре бәкайә кайтды».

Таш үлчәмнәре: 135х44х18. Кабере шулай ук зиратның 15 һәм 16 нчы аллеялары арасында.

Әлеге кабер иясе – Ш. Мәрҗанинең газиз улы. Ул һиҗри 1272 елның 19 рамазанында (1856 елның 10 маенда) дөньяга килгән [5, б. 2]. Башлангыч белемне атасыннан алган, аннан Истамбулда җиде ел укыган. 1882 елның 1 сентябрендә указ (№6436) алып, Ш. Мәрҗани белән бергә имам-мөдәррис вазыйфаларын башкарган, соңрак атасы вафат булгач, аның эшен дәвам иткән [4, б. 2]. Кабер ташындагы тексттан аңлашылганча, аның чын исеме – Мөхәммәд, икенче исеме, ягъни кушаматы – Борһанетдин, күньясе – Әбел-Габбас. «Мәрхүм хуш мәҗлесле, йомшак табигатьле, гыйлем һәм хөрмәт иясе, ачык сөйләү һәм ягымлы телгә ия һәм шулар белән күп мөдәррисләрдән артык иде» [4, б. 2]. Борһан хәзрәт 2 мартта кичке сәгать 5 тә, үпкәсе шешүе сәбәпле, вафат булган [4, б. 2]. Хәзрәтнең үзеннән соң 5 улы, 2 кызы һәм хатыны калган. Бакыйлыкка күчкән вакытында олы улы «Мәрҗани» мәдрәсәсендә мөгаллим, икенчесе

сәүдәгәр булган, калган өчесе сәүдә мәктәбендә укыганнар. Кызларының олысы – Галия – Габдулла бине Галим Агишевта (чыгышы Саратов шәһәреннән) кияүдә, кечесе әле сабый бала булган [4, б. 2].

Галия дамелла Шиһабеддин кызына куелган кабер ташы текстының укылышы түбәндәгечә:

Алгы ягы (уеп язылган):

1) «Мәшһүрә ханым
2) Галийә
3) бинте дамелла
4) Шиһабеддин
5) Мәрҗани
6) кабләл-гурууби
7) мин йәүмил-җүмгати
8) 1343 сәнәи һиҗриййә
9) 71 йәшендә
10) мәдфүнә рахимәһәллааһү
11) Тәгааләә рахмәтән вәәсигаһ».

Текстның хәзерге татар теленә күчермәсе: «Мәшһүрә ханым Галия бинте дамелла Шиһабеддин Мәрҗани кояш батар алдыннан җомга көн һиҗри 1343 елда 71 яшендә җирләнде. Аллаһ Тәгалә аны киң рәхмәте белән рәхим кылсын».

Таш үлчәмнәре: 102(117)х28–31х16–20. Кабере зиратның 17 һәм 18 нче аллеялары арасында.

Кабер иясе – Ш. Мәрҗанинең олы кызы – гыйлемне үз атасыннан алган. Аннан Ш. Мәрҗани аны үз шәкерте Сафиулла бине Габдуллага кияүгә биргән [9, б. 124]. Галиянең икенче исеме, ягъни кушаматы – Хәерниса, күньясе – Өммехәер. Г. Баруди аңа түбәндәгечә характеристика биргән: «Коръәнне яттан белүче, гарәпчәгә сәләтле, аңлау һәм фикер йөртүдә атасыннан күп белемнәр алган, Коръән бастыру эшендә хезмәт итешкән, Нәгыймә исемле бер кыз анасы, күркәм хатын» [1, б. 398].

Яңа Татар бистәсе зиратында Шиһабетдин хәзрәтнең 1945 елда бакыйлыкка күчкән Хавва исемле кызы да җирләнгән. Ташында беренче ике һәм дүртенче юллары гарәп графикасында, калганнары кириллицада язылган. Кабере зиратның 15 һәм 16 нчы аллеялары арасында.

Хавваның икенче исеме, ягъни кушаматы – Ситтел-бәнат, күньясе – Өмме Әйман. Казанның Печән базары мәчете имамы Әбү Яхъя Габдулла Апанаевка кияүгә чыккан. Баруди хәзрәт Хавва ханымны: «Мәгърифәт һәм аң иясе булган хатын», – дип телгә алган [1, б. 398]. Кызы Зәйнәпнең шәҗәрәсе түбәндәгечә: Зәйнәп бинте Габдулла бине Габделкәрим бине Исхак бине Йосыф бине Исмәгыйль бине Апанай [1, б. 398].

Ш. Мәрҗани тәрҗемәи хәлен, эшчәнлеген һәм иҗатын өйрәнгәндә аның белән бәйле чыганакларның берсен дә игътибардан читтә калдырыр-

га ярамый. Шуңа күрә без, бөек галимебез турында материалны җыю һәм тулыландыру йөзеннән, архив документларын, хатирәләрне, язма чыганакларны гына түгел, эпиграфик истәлекләрне дә барларга һәм өйрәнергә тиешбез. Гомумән, тарихи чыганак буларак гарәп язулы кабер ташларының әһәмияте зур. Кыйммәтле тарихи-мәдәни истәлекләр буларак, аларны ничек булса да саклап калу зарур.

## ӘДӘБИЯТ

1. Баруди Г. Ошбу әсәрне туплау мөнәсәбәте белән остаз Галимҗан бине Мөхәммәдҗан әл-Баруди хәзрәтләре язган әсәр // Мәрҗани: фәнни-популяр җыентык. Казан: Җыен, 2010. Б. 550–563.

2. Мәрҗани Ш.Б. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 415 б.

3. Шәрәф Ш. Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле // Мәрҗани: Шиһабеддин әл-Мәрҗани хәзрәтләренең вәлядәтенә йөз ел тулу (1233–1333) мөнәсәбәтилә нәшер ителде. Казан: «Мәгариф» матбагасы: Нашире Салих бине Сабит Гобәйдуллин, 1333 (1915). Б. 2–193.

4. Мәрхүм мулла Борһанетдин Мәрҗани // Кояш. 1916. 4 март. Б. 2.

5. Тәрҗемани К. Борһанетдин Мәрҗани хәзрәт // Кояш. 1916. 6 март. Б. 2–3.

6. Фәхреддин Р. Мәрҗани // Мәрҗани: фәнни-популяр җыентык. Казан: Җыен, 2010. Б. 400–441.

7. Фәхреддинев Р.С. Болгар вә Казан төрекләре. Казан: Татар. кит. нәшр., 1993. 287 б.

8. Шәрәф Б. Мәрҗани хакында җавапларым // Шура. 1911. № 24. Б. 757–759.

9. Шәрәф Ш. Мәрҗанинең тәрҗемәи хәле // Мәрҗани: фәнни-популяр җыентык. Казан: Җыен, 2010. Б. 16–194.

**Автор турында белешмә:** Гайнетдинов Айдар Марсил улы – филология фәннәре кандидаты, өлкән фәнни хезмәткәр, Татарстан Республикасы халыкларының тарихи-мәдәни мирасы бүлеге, ТР ФА Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты (420111, Батурин ур., 7А, Казан, Россия Федерациясе); aydargm@yandex.ru

*Гайнетдинов А.М.* Соңгы еллардагы эпиграфик табышлар:
Ш. Мәрҗани гаиләсе

## ЭПИГРАФИЧЕСКИЕ НАХОДКИ ПОСЛЕДНИХ ЛЕТ: СЕМЬЯ Ш. МАРДЖАНИ

***А.М. Гайнутдинов***

*Институт истории им. Ш. Марджани*
*Академии наук Республики Татарстан*
*Казань, Российская Федерация*
*aydargm@yandex.ru*

Статья посвящена описанию некоторых татарских надмогильных камней XIX – начала XX в., сохранившихся на кладбище Ново-Татарской слободы. Эти памятники установлены на могилы членов семьи ученого Шигабутдина Марджани. В 2017 г. Институтом истории были организованы полевые исследования на кладбище Новотатарской слободы Казани с целью выявления всех сохранившихся эпиграфических памятников. В ходе экспедиций удалось найти и прочитать тексты надгробных камней, установленных в честь видных деятелей, духовных лиц, ученых. Автор выявил и изучил памятники, связанные с Марджани и дал расшифровку их текстов.

**Ключевые слова:** Шигабутдин Марджани, семья Марджани, надмогильные камни, некрополи, эпиграфические памятники, кладбище Ново-Татарской слободы.

**Для цитирования:** Гайнетдинов А.М. Соңгы еллардагы эпиграфик табышлар: Ш. Мәрҗани гаиләсе // Историческая этнология. 2018. Т. 3, № 2. С. 334–344. DOI: 10.22378/he.2018-3-2.334-344

**Сведения об авторе:** Гайнутдинов Айдар Марсилевич – кандидат филологических наук, старший научный сотрудник, отдел историко-культурного наследия народов Республики Татарстан, Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ (420111, ул. Батурина, 7А, Казань, Российская Федерация); aydargm@yandex.ru

## SOME EPIGRAPHIC MONUMENTS ASSOCIATED WITH SH. MARJANI

***A.M. Gainutdinov***

*Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences*
*Kazan, Russian Federation*
*aydargm@yandex.ru*

The article is devoted to the description of some Tatar grave stones of the 19$^{th}$ and early 20$^{th}$ centuries, preserved in a cemetery of New Tatar Sloboda in Kazan. The given monuments are set on the graves of scholar Shihabutdin Marjani’s family members of. In 2017 the Institute of History organized research field trips in the cemetery of New Tatar Sloboda in Kazan in order to identify all the preserved epigraphic monuments. During the expeditions it was possible to find and read the texts of the tombstones

installed in honor of eminent personalities, clergymen, and scientists. For example, we can mention the monuments related to such great personalities like Sh. Marjani. The author personally identified, explored the monuments associated with Marjani and provided a transcript of their texts.

**Keywords:** Shihabutdin Marjani, Marjani's family, Tatar epigraphy, tombstones, epitaphs, descendants, monuments, New Tatar Sloboda cemetary.

**For citation:** Gainutdinov A.M. Some epigraphic monuments associated with Sh. Marjani. *Istoricheskaya etnologiya – Historical Ethnology*, 2018, vol. 3, no. 2, pp. 334–344. DOI: 10.22378/he.2018-3-2.334-344

REFERENCES

1. Barudi G. Oshbu äsärne tuplau monäsäbäte belän ostaz Galimjan bine Mohämmädjan äl-Barudi häzrätläre yazgan äsär [The article written by Galimjan bine Mukhammadjan al-Barudi to compile the given work]. Märjani: fänni populyar jyiyntyk [Marjani: popular science collection]. Kazan, 2010. 550–563 p. (In Tatar)

2. Märğani Sh.B. *Məstäfadel-ähbar fi ähvali Kazan vä Bolgar (Kazan häm Bolgar hälläre turynda fajdalanylgan häbärlär)* [A fount of information about the affairs of Kazan and Bulgar]. Kazan, Tatar Book Publ. House, 1989. (In Tatar)

3. Sharaf Sh. Märjaninen tärjemäi häle [Biography of Marjani]. *Märjani*: *fänni populyar jyiyntyk* [Marjani: a popular science collection]. Kazan, 1333 (1915), pp. 2–193. (In Tatar)

4. Märhum mulla Borhanetdin Märjani [Marhum mulla Borhanetdin Marjani]. *Koyash – The Sun*. 1916. 4 March. 2 p. (In Tatar)

5. Tarjemani K. Borhanetdin Märjani häzrät [Borhanetdin Marjani]. *Koyash – The Sun*. 1916. 6 March. 2–3 p. (In Tatar)

6. Fakhretdin R. Märjani [Marjani]. *Märjani: fänni populyar jyiyntyk* [Marjani: a popular science collection]. Kazan, 2010, pp. 400–441. (In Tatar)

7. Fakhretdin R. Bolgar wä Kazan torekläre [The Turks of Bolgar and Kazan]. Kazan, 1993. 287 p. (In Tatar)

8. Sharaf B. Märjani haqynda jawaplarym [My answers about Marjani]. *Shura – The Advice*. 1911. 6 March, pp. 757–759. (In Tatar)

9. Sharaf Sh. Märjaninen tärjemäi häle [Biography of Marjani]. *Märjani: fänni populyar jyiyntyk* [Marjani: a popular science collection]. Kazan, 2010, pp. 16–194. (In Tatar)

**About the author:** Aidar M. Gainutdinov is a Candidate of Science (Philology), Senior Research Fellow, Department of Historical and Cultural Heritage of the Peoples of Tatarstan, Sh. Marjani Institute of History of the Tatarstan Academy of Sciences (7A, Baturin St., Kazan 420111, Russian Federation); aydargm@yandex.ru